| | | |
|---|---|---|
| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |

| | | |
|---|---|---|
| **ПОСТАНОВЛЕНИЕ**<br>**10.02.2026** | Зеленодольск<br>шәһәре | **КАРАР**<br>**№ 402** |

Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2024 елның 19 июлендәге «Зеленодольск муниципаль районы муниципаль мәгариф оешмалары хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәләрне раслау хакында» 1899 номерлы карарына (Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2025 елның 07 мартындагы 597 номерлы, 2025 елның 24 апрелендәге 1120 номерлы, 2025 елның 12 декабрендәге 3495 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2025 елның 19 июнендәге «Татарстан Республикасы дәүләт белем бирү оешмалары хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турында» 2018 елның 31 маендагы 412 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарына үзгәрешләр кертү хакында» 444 номерлы карарын үтәү йөзеннән, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2024 елның 19 июлендәге «Зеленодольск муниципаль районы муниципаль мәгариф оешмалары хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәләрне раслау хакында» 1899 номерлы карарына (Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2025 елның 07 мартындагы 597 номерлы, 2025 елның 24 апрелендәге 1120 номерлы, 2025 елның 12 декабрендәге 3495 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) (алга таба – Карар) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. «Зеленодольск муниципаль районы муниципаль мәгариф оешмалары хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турында» нигезләмәгә әлеге карарның 1 нче кушымтасында каралганча үзгәрешләр кертергә;

1.2. «Зеленодольск муниципаль районының мәктәпкәчә мәгариф оешмалары хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турында» нигезләмәгә әлеге карарга 2 нче кушымтада каралганча үзгәрешләр кертергә;

1.3. «Зеленодольск муниципаль районының өстәмә белем бирү мәгариф оешмалары хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турында» нигезләмәгә әлеге карарның 3 нче кушымтасында каралганча үзгәрешләр кертергә.

2. Муниципаль учреждение җитәкчеләренә үз локаль актларын әлеге карарга туры китерергә.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә һәм 2025 елның 01 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Әлеге карарны Зеленодольск муниципаль районы Советы аппаратының җәмәгатьчелек һәм массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлегенә Интернет челтәренең Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми (http://pravo.tatarstan.ru) порталында һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы рәсми (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) сайтында урнаштырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче З.Ф. Хәбибуллин

Зеленодольск муниципаль районы
Башкарма комитетының
2026 елның 10 февралендәге
402 номерлы карарына
1 нче кушымта

«Зеленодольск муниципаль районы муниципаль мәгариф оешмалары хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турында» нигезләмәдә:

3.2 пунктның икенче абзацында "(тормыш иминлеге нигезләре, хәрби чакырылышка кадәр әзерлек буенча)" сүзләрен " Ватанны саклау һәм иминлек нигезләре" сүзләренә алмаштырырга;

3.3 пунктта:

3.3.1 пунктчасының беренче абзацында "тормыш иминлеге нигезләре һәм хәрби чакырылышка кадәр әзерлек буенча оештыручы укытучыларга " сүзләрен "Ватанны саклау һәм иминлек нигезләре оештыручы укытучыларга" сүзләренә алмаштырырга;

3.3.2 пунктчасының беренче абзацында " тормыш иминлеге нигезләре һәм хәрби чакырылышка кадәрге әзерлек буенча укытучы-оештыручыларга " сүзләрен "Ватанны саклау һәм иминлек нигезләре укытучы-оештыручыларга" сүзләренә алмаштырырга;

3 нче таблицаның "Белем бирү оешмалары, шул исәптән югары белем бирү оешмалары, югары белем бирү хәрби белем бирү оешмалары һәм хәрби һөнәри белем бирү оешмалары, өстәмә һөнәри белем бирү оешмалары (белгечләрнең квалификациясен күтәрү); медицина оешмалары һәм социаль хезмәт күрсәтү оешмалары: балалар йортлары, шифаханәләр, клиникалар, поликлиникалар, хастаханәләр һ.б" 2 нче графасында. "( тормыш иминлеге нигезләре һәм хәрби чакырылышка кадәрге әзерлек буенча) сүзләрен "Ватанны саклау һәм иминлек нигезләре "сүзләренә алмаштырырга;

5.2 пунктның 5.2.6 подпунктчаның икенче абзацында ("тормыш иминлеге нигезләре, чакырылышка кадәрге әзерлек буенча") сүзләрен " Ватанны саклау һәм иминлек нигезләре " сүзләренә алмаштырырга;

5.7 пунктының 5.7.9 пунктчасындагы 9 нчы таблицаның 3.19 пунктындагы 2 нче графасында " тормыш эшчәнлеге "сүзләрен" Ватанны саклау һәм "сүзләренә алмаштырырга.

Зеленодольск муниципаль районы
Башкарма комитетының
2026 елның 10 февралендәге
402 номерлы карарына
2 нче кушымта

«Зеленодольск муниципаль районының мәктәпкәчә мәгариф оешмалары хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турында»Нигезләмәсендә:

3 нче таблицаның "Белем бирү оешмалары, шул исәптән югары белем бирү оешмалары, югары белем бирү хәрби белем бирү оешмалары һәм хәрби һөнәри белем бирү оешмалары, өстәмә һөнәри белем бирү оешмалары (белгечләрнең квалификациясен күтәрү); медицина оешмалары һәм социаль хезмәт күрсәтү оешмалары: балалар йортлары, шифаханәләр, клиникалар, поликлиникалар, хастаханәләр һ.б" 2 нче графасында. "( тормыш иминлеге нигезләре, хәрби чакырылышка кадәрге әзерлек буенча) сүзләрен " Ватанны саклау һәм иминлек нигезләре "сүзләренә алмаштырырга;

5.2 пунктның 5.2.6 пунктчасындагы икенче абзацында "(тормыш иминлеге нигезләре, хәрби чакырылышка кадәрге әзерлек буенча)" сүзләрен "Ватанны саклау һәм иминлек нигезләре" сүзләренә алмаштырырга.

Зеленодольск муниципаль районы
Башкарма комитетының
2026 елның 10 февралендәге
402 номерлы карарына
3 нче кушымта

«Зеленодольск муниципаль районының өстәмә белем бирү мәгариф оешмалары хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турында» нигезләмәдә:

3 нче таблицаның "Белем бирү оешмалары, шул исәптән югары белем бирү оешмалары, югары белем бирү хәрби белем бирү оешмалары һәм хәрби һөнәри белем бирү оешмалары, өстәмә һөнәри белем бирү оешмалары (белгечләрнең квалификациясен күтәрү); медицина оешмалары һәм социаль хезмәт күрсәтү оешмалары: балалар йортлары, шифаханәләр, клиникалар, поликлиникалар, хастаханәләр һ.б" 2 нче графасында. "(тормыш иминлеге нигезләре, хәрби чакырылышка кадәрге әзерлек буенча) сүзләрен " Ватанны саклау һәм иминлек нигезләре "сүзләренә алмаштырырга;

5.2 пунктның 5.2.6 пунктчасындагы икенче абзацында "(тормыш иминлеге нигезләре, хәрби чакырылышка кадәрге әзерлек буенча)" сүзләрен "Ватанны саклау һәм иминлек нигезләре" сүзләренә алмаштырырга.